## ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **10.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй авыл җирлеге составына керүче Метрәй торак пунктына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Метрәй авыл җирлеге Метрәй торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Метрәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 700 (жиде йоз) сум күләмендә үзара салым кертергә. I, II төркем инвалидларга, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларга, армия хезмәте узучыларга; көндезге бүлектә белем алучы студентларга 350 (өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүгә;
- мәдәният оешмалары хезмәтләре белән ял вакытын оештыру һәм халыкны тәэмин итү өчен шартлар тудыруга;
- Физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, авылы җирлегендә рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыруга;
- рәсми мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыруга;
- төзекләндерүне оештыруга;
- ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тотуга;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүгә;
- торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә;
- күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыруга».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда , Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Метрәй авылы, Пушкин урамы, 50 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Метрәй авыл җирлеге башлыгы Гильфанов А.А.